ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01. 03. 2021 г.Мензелинск № 66

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясе турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 19 февралендәге №04 номерлы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясен булдыру турында” Минзәлә муниципаль районы Советы карары нигезендә Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясе составы (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламенты (2 нче кушымта).

3.Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясенең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.

4.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2011 елның 25 декабрендәге 71 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, административ комиссия рәисе Д.А.Чухланцевка йөкләргә.

Җитәкче К.Р.Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 1 март
66 номерлы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
административ комиссиясе
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Чухланцев Д.А. | Комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Ягафаров Р.Ф. | Комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе (килешенү буенча) |
| 3. | Петров В.К. | Комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы урынбасары |
| 4. | Кириченко М.Р. | Комиссиянең җаваплы сәркатибе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты административ комиссиясенең баш белгече |
| 5. | Салдаева Р.Я. | Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәр башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| 6. | Бадриева Р.Р. | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советының юридик бүлеге начальнигы (килешенү буенча) |
| 7. | Токарев М.О. | ТР Минзәлә муниципаль районында коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ТР Минзәлә муниципаль район башлыгы ярдәмчесе (килешенү буенча) |
| 8. | Шамсуллина Н. В. | Россия УФССП Татарстан Республикасы буенча Минзәлә РОСП суд приставы-башкаручысы (килешенү буенча) |
| 9. | Тимерханов А.Ф. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ДУнең Актаныш һәм Минзәлә муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлеге начальнигы (килешенү буенча) |

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 1 март
66 номерлы карарына 2 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламенты**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1.Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы административ комиссиясе (алга таба - административ комиссия) эшчәнлегенең эчке мәсьәләләрен, шул исәптән административ комиссия утырышын алып бару тәртибен, административ комиссия әгъзалары арасында эшне бүлүне билгели.

1.1. Административ комиссия «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелә.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карарлары, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, Минзәлә муниципаль районының муниципаль хокукый актлары, башка норматив-хокукый актлар, шулай ук әлеге регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында Кодексы, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турында Кодексында күздә тотылган административ хокук бозулар турында эшләрне карау өчен булдырылган даими гамәлдә булган коллегиаль орган булып тора. Һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы чикләрендә гамәлдә була.

1.4. Административ хокук бозулар турында һәр эшне Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында Кодексы, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турында Кодексы нигезендә төрле яклап, тулы. Объектив һәм үзвакытында тикшерү, чыгарылган карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү административ комиссиянең бурычлары булып тора. Административ хокук бозуның сәбәбе һәм аны кылуга китергән шартлар ачыкланган очракта, тиешле оешмаларга һәм тиешле вазыйфаи затларга күрсәтелгән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү турында хәбәрнамә чыгарыла.

1.5. Административ комиссияне булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләре гамәлгә ашырылуны контрольдә тотуны

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, административ комиссиянең җаваплы сәркатибеннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан тора, аларны административ комиссиягә керү турында гариза нигезендә Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе билгели.

2.2. Административ комиссия үз эшчәнлеген гамәлдәге кануннар нигезендә башкара. Административ комиссиянең агымдагы эшчәнлеге рәис раслаган план нигезендә алып барыла.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм сан составы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә 5 кешедән ким булмаган санда билгеләнә һәм так санда булырга тиеш.

2.4. Административ комиссия составына даими штат нигезендә административ комиссиянең җаваплы сәркатибе керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары административ комиссиядә, гамәлдәге Регламентның 2.5.пунктында каралган очраклардан тыш, җәмәгать башлангычы нигезендә эшлиләр.

2.5. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын җирле бюджет акчалары хисабыннан даими түләүле нигездә башкара алалар.

2.6. Административ хокук бозу турында эшне тикшергәндә комиссия әгъзаларының хокуклары тигез. Комиссия утырышларын әзерләгәндә; алдан. Комиссия утырышна кадәр, тикшерүгә чыгарылган административ хокук бозулар турында эш материаллары белән танышырга; эш торышын өстәмә ачыклау зарурлыгы туган очракларда, эшне тикшерүне кичектерү турындагы тәкъдимнәрне комиссия рәисенә белдерү; комиссиянең барлык утырышларында катнашырга бурычлы (Административ комиссия Рәисенә алдан хәбәр итеп, катнаша алмауның сәбәбен бәян иткән очраклардан тыш); административ хокук бозу турында эш буенча катнашучы затларга сораулар бирергә; каралган эшләр буенча комиссия кабул иткән карарларны, билгеләмәләрне һәм гаризаларны тикшерүдә катнашырга; каралган эшләр буенча комиссия кабул иткән карарларны, билгеләмәләрне һәм гаризаларны комиссия кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга; Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннарында каралган башка вәкаләтләрне башкарырга вәкаләтле.

2.7. Административ комиссия рәисе комиссия әгъзалары вәкаләтләреннән файдалана. Шулай ук: комиссия эшчәнлеге белән идарә итүне гамәлгә ашыра; комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра; комиссия эшен планлаштыра; комиссия утырышын билгели; рәис урынбасары, административ комиссиянең җаваплы сәркатибе һәм комиссия әгъзалары арасында бурычларны билгели; аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законында каралган вәкаләтләр чикләрендә билгели; административ комиссиянең һәр утырышының көн тәртибен

раслый; комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны, билгеләмәләрне һәм гаризаларны имзалый; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар һәм гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә комиссия мәнфәгатьләрен яклый; комиссия исеменнән ышаныч язуыннан башка үз компетенциясе чикләрендә эш итә, аны барлык учреждениеләрдә һәм оешмаларда күрсәтә; Административ комиссия әгъзаларына гомуми юрисдикция судларында һәм башка органнарда күрсәтү өчен ышанычнамә бирә; гамәлдәге кануннар белән билгеләнгән, үз компетенциясе чикләрендә Административ комиссия эшен оештыру буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра; комиссия эшчнлеге өчен персональ җаваплылык тота.

2.8. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук: комиссия рәисе йөкләмәләрен үти; үзе булмаган вакытта яисә үз вазыйфаларын үтәү мөмкин булмаганда комиссия рәисе вазыйфаларын башкара.

2.9. Комиссиянең җаваплы сәркатибе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук: административ хокук бозулар турында эшләрне комиссия утырышында карауга әзерлекне башкара; Комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмләрен үти; комиссия эшенең техник тәэмин ителешен гамәлгә ашыра; комиссия эшләрен алып бара; комиссия әгъзаларына һәм административ хокук бозу турында эш буенча катнашучы затларга эшнең каралу вакыты һәм урыны турында хәбәр итә; Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында Кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, тикшерелә торган административ хокук бозулар турында комиссия чыгарган каралар, билгеләмәләр һәм гаризалар проектларын әзерләүне һәм рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра; карарларның күчермәләрен тапшыруны яисә киер җибәрүне тәэмин итә; эш буенча катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның комиссия чыгарган карарлар, билгеләмәләр һәм гаризаларның үтәлшене контрольдә тотуны гамәлгә ашыра; Административ комиссия эшчәнлеге өлкәсендә статистик учет алып бара; Административ комиссия Рәисе биргән ышанычнамә нигезендә гомуми юрисдикция судларында һәм башка органнарда аның вәкиле булып тора.

2.10. Административ комиссия килгән кешеләрне кабул итә ала. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе нигезендә билгеләнә.

Административ комиссиягә гражданнардан һәм юридик затлардан килгән дәгъвалар һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге кануннар нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

2.11. Карар чыгарылганга кадәр гариза тапшыручыларга административ хокук бозулар турында эшләрне тапшыру тыела (кануннарда каралган очраклардан тыш).

2.12. Административ комиссия утырышы барышында кино-, видео- һәм фотога төшерү рәис рөхсәте белән башкарыла.

## 3. Административ комиссия утырышы чакырылышы һәм уздыру тәртибе

3.1. Татарстан Республикасының 30.12.2005 елдагы “Белем бирү һәм административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру буенча муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Татарстан республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 144-ЗРТ Законы нигезендә, административ хокук бозулар турында эшләр рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип, комиссия әгъзалары, эштә катнашучы башка затлар, аларның вәкилләре составында Административ комиссия утырышларында карала.

3.2. Административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында карар аның рәисе, ә ул булмаганда – рәис билгеләгән рәис урынбасары тарафыннан, беркетмәләр һәм административ хокук бозулар турында башка материалларның керүенә карап, һәм ТР КоАПта каралган срокларда кабул ителә.

3.3. Административ комиссия утырышында административ комиссия рәисе рәислек итә, ә ул булмаган очракта – административ комиссия рәисе урынбасары.

3.4. Административ комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, ачык формада уза. Аларда гавами мәгълүмат чаралары катнаша ала.

3.5. Административ хокук бозу турында эшне карау өчен билгеләнгән вакытта рәислек итүче комиссия утырышын ача, комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокукларын һәм бурычларын аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, эштә катнашучыга хокукларын һәм бурычларын аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гаризалары, үтенечнамәләре булу булмавын ачыклый; эшнең барлык үзенчәлекләрен тулы һәм төрле яктан ачыклауга ярдәм итеп, утырыш белән җитәкчелек итә, утырыш барышында тиешле тәртипне тәэмин итә.

3.6. Административ комиссия утырышы, Административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының өчтән бер өлеше катнашкан очракта, тулы хокуклы булып санала.

3.7. Беркетмәне тикшерү административ материал торышы турында рәислек итүче докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң Административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.8. Административ эш буенча докладтан соң комиссия беркетмәне тикшерүгә күчә. Анда бары тик комиссия әгъзалары гына катнаша.

3.9. Административ комиссиянең һәр утырышында җаваплы сәркатип алып бара торган беркетмә төзү мәҗбүри.

3.10. Административ хокук бозу турында эшне кичектерү, тәнәфес игълан итү һәм эшне карауны кабаттан башлау гамәлдәге кануннарның таләпләрен үтәп башкарыла.

3.11. Административ хокук бозу турында эш чынлыкта каралганнан соң, Административ комиссия карар чыгару өчен тәнәфес ясый, бу турыда рәислек итүче утырыш залында катнашучыларга хәбәр итә.

3.12. Комиссия утырышы атна саен пәнҗешәмбе көннәрдә 14.00 сәгатьтән гамәлгә ашырыла, әгәр комиссия тарафыннан башка карар кабул ителмәсә.

## 4. Административ комиссия карарлары

4.1. Административ комиссия карарлары административ комиссия рәисе тарафыннан, ул булмаган очракта, - административ комиссия рәисе урынбасары һәм административ комиссиянең җаваплы сәркатибе тарафыннан имзалана.

4.2. Карар, административ хокук бозу турында эш буенча билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының күпчелек тавыш бирүе аша кабул ителә.

4.3. Бер үк вакытта утырышта катнашучы затларга, һәм аларның вәкилләренә Административ комиссия карарларына шикаять белдерү тәртибе аңлатыла.

4.4. Карарның күчермәсе физик затка, яисә физик затның законлы вәкиленә, яисә карар чыгарылган юридик затның законлы вәкиленә имза куеп тапшырыла, яисә күрсәтелгән карар чыгарылган көннән соң өч көн эчендә күрсәтелгән затларга җибәрелә.

4.5. Административ комиссия карарлары күчермәләренең үзвакытында тапшырылуын һәм җибәрелүен контрольдә тоту җаваплы сәркатипкә тапшырыла.

4.6. Законлы көченә кергән Административ комиссия карарларының үтәлеше Россия Федерациясе кануннарын нигезендә башкарыла.

4.8. Административ комиссия карарларына дәгъвалар яисә протестлар Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында Кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

## 5. Административ җәза салыну турында карарның үтәлеше

5.1. Административ хокук бозу турында эш буенча Административ комиссия Карары дәүләт хакимиятенең барлык органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

5.2. Административ хокук бозу турында эш буенча карар законлы көченә кергән вакыттан үтәлергә тиеш.

5.3. Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында Кодексның 31.5 статьясында каралган чигерү яисә өлешләп чигерү срогы чыккан көннән соң яисә административ әтраф салу турында карар көченә кергәннән соң түләнергә тиеш.

5.4. Административ штраф суммасы административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан кертелә яисә банктагы тиешле счетка яки башка кредит оешмасына күчерелә.

5.5. Административ хокук бозу турында эш буенча карарга дәгъва карарның күчермәсе тапшырылган яисә алынган көннән соң ун тәүлек эчендә бирелергә мөмкин.

5.6. Административ штрафны түләү турында раслаучы документ булмаган очракта, карар законлы көченә кергәннән соң алтмыш көн узгач, Административ комиссия федераль кануннарда каралган тәртиптә административ штраф суммасын түләтү өчен суд пристав-башкаручыга тиешле материалларны җибәрә

## 6. Административ комиссиянең вәкаләтләре срогы

6.1. Комиссия вәкаләтләре срогы административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел дәвам итә.

6.2. Күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң административ комиссия комиссиянең яңа составының беренче утырышына кадәр үз вәкаләтләрен башкаруын дәвам итә.

## 7. Административ хокук бозуларны профилактикалау

7.1. Административ хокук бозуларны булдырмау максатларында, административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, Суд приставлары федераль хезмәт идарәсенең территориаль органнары, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы. Башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән җайга сала.

7.2. Административ комиссия утырышларны рәис раслаган график нигезендә урынга чыгып, шул исәптән, муниципаль район җирлекләрендә уздыра.

7.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген гавами мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эш оештыра.